**ГЛАВА**
**НИЖНЕТИМЕРЛЕКСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422670, Республика Татарстан,
Рыбно-Слободский район, ул Советская., дом 4,
с.Верхний Тимерлек

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТҮБӘН ТЕГЕРМӘНЛЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

422670,Татарстан Республикасы,
Балык Бистәсе районы, Совет урамы, 4 нчы йорт,
Югары Тегермәнлек авылы

**Тел.: (8-4361) 28001 , факс: (8-4361) 28001 , эл.адрес: Ntim.Rs@tatar.ru**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

. 2020 елның 05 ноябре Югары Тегермәнлек авылы № 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Югары Тегермәнлек, Түбән Тегермәнлек авыл торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Түбән Тегермәнлек авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2020 елның 18 ноябрендә 11 сәг. 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Түбән Тегермәнлек авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2020 елның 19 ноябрендә 11 сәг. 00 минутка билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Югары Тегермәнлек авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2020 елның 18 ноябрендә 14 сәг. 00 минутка билгеләргә.
4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Югары Тегермәнлек авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2020 елның 19 ноябрендә 14 сәг. 00 минутка билгеләргә.
5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү территориаль билге буенча гамәлгә ашырылуын расларга.

6. Гражданнар җыены каравына куела торган сорауны расларга:

Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Югары Тегермәнлек , Түбән Тегермәнлек авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, 80 яше тулган кешеләрдән гайре) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Югары Тегермәнлек авылының Фрунзе,Титов, Совет урамнары , Түбән Тегермәнлек авылының Мәктәп урамы юллары ремонты өчен вакланган таш сатып алуга;
- 12 берәмлектә каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен чүп савытлары сатып алуга һәм урнаштыруга;
- кышкы чорда Югары Тегермәнлек , Түбән Тегермәнлек авылларында юлларны кардан чистартып торуга;
- Түбән Тегермәнлек авылында ял итү мәйданчыгына инвентарь сатып алуга.

"ЯКЛЫЙМ" "КАРШЫ"

7. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең түбәндәге адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Югары Тегермәнлек авылы, Совет урамы, 72а йорты, Түбән Тегермәнлек авылы, Мәктәп урамы, 7б йорты һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда.

8. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Башлыгы А.Ш.Альмиев